БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

«29» 01 2022 ел № 68

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының тукланыуын оештыру турында» 2016 елның 30 декабрендәге 275 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

Укучыларны баланслы кайнар ризык белән тәэмин итү, аларның сәламәтлеген саклау, муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын күтәрү, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декарендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Халыкның җәмәгать тукланыуын оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр» 2.3/2.4.3590-20 СанПиН таләпләрен үтәү максатларында, «2022 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2021 елның 7 сентябрендәге 842 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының тукланыуын оештыру турында» 2016 елның 30 декабрендәге 275 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «2022 елның 1 гыйнварыннан Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын һәр уку көненә 8 сум 30 тиен субсидиядән һәм ата-ана түләвеннән торган кайнар аш белән тәэмин итәргә».

2. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының тукланыуын оештыру турында» 2016 елның 30 декабрендәге 275 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының тукланыуын оештыру тәртибе турында

нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.1. 1.4 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 4 һәм аннан күбрәк балигъ булмаган бала тәрбияләүче, аз керемлелек буенча пособие алучы аз керемле, күпбалалы гаиләләрдәге балаларга».

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм http://baltasi.tatarstan.ru адресы буенча Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов